# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
## Бирючевка авыл җирлеге

Бирючевка авылы № 88 23.03.2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Бирючевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 31.08.2017 №62 Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советы карары белән расланган муниципаль вазыйфалар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларына белешмәләр бирү «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру тәртибенә үзгәреш кертү турында

2012 елның 03 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон нигезендә

Бирючевка авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Бирючевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 31.08.2017 №62 Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советы карары белән расланган муниципаль вазыйфалар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларына белешмәләр бирү «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру тәртибенә үзгәреш кертеп 3 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«г) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган (килешү эшләнгән) акчалар алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч ел эчендә муниципаль вазыйфаны биләүче затның гомуми кеременнән артып китсә. "

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Рәис М.Г.Нуреева